ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14 11 2022 г. № 283

Түбән Кама шәһәре башкарма комитетында күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым Административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2021 елның 29 ноябрендәге 347 номерлы карары белән расланган социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2021 елның 20 декабрендәге 377 номерлы карары белән расланган социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең аерым Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Регламентның 1.5 пунктындагы 8 абзацында «(алга таба – гариза)» сүзен «(алга таба – гариза, сорату)» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентның 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган соратуны формат-логик тикшерү гариза бирүченең соратуның һәрбер электрон формасы кырын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал соратуның электрон формадагы дөрес тутырылмаган кырын ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры соратуның электрон формасында мәгълүмати белдерү аша хәбәр ителә.».

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге җитәкчесе Р.Ф. Хәйруллинга йөкләргә.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881